МОУ «Кульбашинская основная общеобразовательная школа

Утверждаю:
Директор школы
____________/Сайфуллин Д.Р./
«______»__________2023 г.

Рассмотрено на заседании ШМО
учителей-предметников
Протокол №1 от 5 сентября 2023
____________ /Хасанова М.Ш./

Сайфуллин Дамир Раянович
C=RU, O="МОУ "" Кульбашинская основная общеобразовательная школа""", CN=Сайфуллин Дамир Раянович, E=kulbash-shkola@rambler.ru
я подтверждаю этот документ своей удостоверяющей подписью
д.Кульбаш
2023.11.11 13:51:22+03'00'

# Рабочая учебная программа

## по родной литературе
## для 7 класса

**Составила:** Файзрахманова Радина Ильдусовна - учитель родной литературы

2023/2024 учебный год

## Уку предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- әдәбиятның кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз халкыңның тарихы, мәдәнияте, әдәбияты белән горурлану хисләре булдыру;
- милләткә мәхәббәт хисенең тирәнлеген, милләткә хезмәт итүнең бөеклегенә төшенү;
- әсәр геройлары үрнәгендә үзеңдә уңай сыйфатлар булдыру;
- янәшәдәге кешеләргә игътибарлылык, дусларга карата хөрмәт хисе булдыру, һөнәр турында җитди караш формалаштыру;
- әсәрдә гореф-гадәтләр һәм йолаларның бирелеше һәм аларга карата ихтирам хисләре булдыру;
- әсәргә салынган идеянең кыйммәтен кабул итү аша үз-үзеңне тәрбияләү;
- әдәби әсәрләр нигезендә әхлак тәрбиясе һәм патриотик тәрбия алу;
- әдәби әсәрләр үрнәгендә өлкән буынга ихтирамлы булу, гомумкешелек сыйфатларына ия булу;
- илебез азатлыгы өчен көрәшкән сугышчыларга хөрмәт хисе булдыру, Ватаныбыз тарихына сакчыл караш булдыру;
- рухи байлыкның зур бәхет булуын аңлау.

**Метапредмет нәтиҗәләр**:

Әдәбиятны иҗтимагый һәм мәдәни тормыш-күренешләре белән бәйлелектә аңлау.

**Танып-белү гамәлләре:**

- гомум уку гамәлләре (танып белү мәсьәләсен аңлау, төрле жанрдагы текстлардан кирәкле мәгълүматны аерып чыгару, өйрәнелә торган материал эчендә төп фикерне билгеләү, белемне структуралаштыру, нәтиҗәләр, гомумиләштерүләр ясау);
- логик уку гамәлләре (билгеләрне аерып чыгару максаты белән объектларны анализлау, объектларны чагыштыру, классификацияләү критерийларын эшләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү);
- проблема кую һәм аны хәл итү (проблеманы тәгъбир итү, иҗади һәм эзләнү характерындагы проблемаларны хәл итү чараларын мөстәкыйль эшләү);

**Коммуникатив гамәлләр:**

- хезмәттәшлек итү;
- тел нормаларына туры китереп, монолог төзү һәм диалогта катнашу осталыгына ия булу;
- үз фикерләрен тәгъбир итү;
- текст эчтәлеген өлешләргә бүлеп сөйләү;
- фикерләрне дәлилләп җиткерү;
- сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү;
- фикерләрне эзлекле рәвештә, , мисаллар белән дәлилләп, телдән һәм язмача формалаштыру;

**Регулятив гамәлләр:**

- уку мәсьәләсен кую;
- фаразлау;
- үз эшчәнлекне планлаштыру һәм оештыру;
- анализ барышын төзү;
- үзенең һәм башкаларның эшчәнлекләрен контрольдә тотып бәяли алу;
- үзанализ һәм үзбәя ясау.

**Предмет нәтиҗәләр:**

- халык авыз иҗаты – дастан жанрын үзләштерү, аның матур әдәбият белән уртак сыйфатларын һәм үзенчәлекләрен аера белү;

- әдәбият аша образлы фикерли алу;
- әдипләрнең тормышы һәм иҗаты турында мәгълүматлы булу, аларны истә калдыру;
- әдәби әсәрнең эчтәлеген белү, аңлау, төп фикерне таба белү;
- әдәби әсәрне эчтәлек һәм форма берлегендә аңлый белү;
- әдәби әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, әсәр композициясе үзенчәлекләренкүрә һәм аера белү.
- автор позициясен ачыклый белү;
  әдәби әсәрләрнең кыйммәтен ачыклау, әдәбиятта тоткан урынын билгели белү;
  төп образларга бәя бирү алу;
- әдәбият теориясе буенча билгеле бер күләмдә теоретик белемгә ия булу

**Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр**

**Укучылар өйрәнәчәк:**

- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади, сәнгатьле уку, аларга карата укучыларда мөстәкыйль мөнәсәбәт булдыру;
- әдәби әсәрне сюжет-композиция, образлар бирелеше, тел-стиль ягыннан анализлау;
- шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү;
- план төзү һәм әсәрләр турында бәяләмә, сочинение элементлары белән изложение язу;
- сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлын, иҗатын сөйләү:
- фольклор әсәрләренең жанрын һәм аларга хас үзенчәлекләрне тану;
- әдәби әсәрнең төрен, жанрын билгеләү һәм фикерне исбатлау;
- төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү;
- әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение яза белү.

**Укучыларөйрәнергә мөмкинчелек алачак:**

- әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан сөйләү;
- сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү;
- фольклор әсәрләренең жанрын һәм аларга хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәр төрләрен, жанрларын таный, аера, аларга хас үзенчәлекләрне таба белү, фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу.
- әдәби әсәрнең сюжетын, анда сурәтләнгән вакыйгаларны, характерларны эзлекле сөйләп бирә алу; төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар) белән максатчан эшли белү;
- вакытлы матбугат материалларына максатчан мөрәҗәгать итә алу;
- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле укый белү;
- укыганны телдән сурәтләп бирә алу;
- укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү һәм әсәрләргә кагылышлы фикерләрне язмача бирү, сочинение элементлары белән изложение язу;
- әдәби әсәрне тормыштан алган фикер-карашлар, хис-кичерешләр белән бәйләп сочинение язу;
- проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, әсәр композициясе үзенчәлекләрен күрә, аера белү;

- әдәби әсәрне сюжет–композиция, образлар бирелеше, тел–стиль ягыннан анализлау;
- тулы текстны анализлау.

## Программаның эчтәлеге

**Сәнгать төре буларак әдәбият.** Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып–белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы. **(1 сәгать).**

**Халык авыз иҗаты.** Дастан жанрына хас сыйфатлар, аның төркемчәләре. Тарихи дастан буларак «Идегәй» дастаны (өзекләр). **(3 сәгать).**

**XX гасыр башы**нда сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу. (Күзәтү характерында лекция **(1 сәгать).**

**Г.Тукай тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.**«Милләтә», “Милли моңнар”, “Өзелгән өмид”, “Шагыйрь”, “Театр” шигырьләре. Гражданлык лирикасы, автор позициясе төшенчәләре. **(3 сәгать).**

**Н.Думавиның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү..**«Яшь ана» хикәясе.Әсәрдә хикәя жанры үзенчәлекләренең чагылышы.Әдәби әсәрдәге образлылык. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар.

**(3 сәгать).**

**Ш.Камалның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.**«Акчарлаклар» повесте (өзекләр). Әсәрдә жанр үзенчәлекләренең чагылышы. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Табигать образы, әйбер образы. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт образы (хронотоп). **(3 сәгать).**

**Чор: 1920-1930 еллар әдәбияты. Әдәби барышка тәэсир иткән тарихи сәбәпләр. Аларның әдәбиятны каршылыклы үсешкә китерүе.** Әдәби әсәрләр төрлелек: милли традицияләрне дәвам иттерүче һәм яңа идеология кысаларында иҗат ителгән әсәрләр.**(Күзәтү төсендәге лекция 1 сәгать).**

**Һ.Такташның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** “Мокамай” поэмасы. Лиро-эпик жанр - поэма. Лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт.Текст: эпиграф, багышлау. **(2 сәгать).**

**Г.Исхакыйныңтормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.**«Җан Баевич» комедиясе. Драма төренең комедия жанры турында белгәннәрне тулыландыру. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). **(2 сәгать).**

**Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү**“Кызыл чәчәкләр” повесте.Эпик жанрлар турындагы белемнәрне киңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре**. (2 сәгать).**

**Чор әдәбияты.** XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы, аның тарихи сәбәпләре.Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр.**(Күзәтү характерында лекция. 1 сәгать).**

**С.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.**«Әнкәй», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигырьләре. Лирик жанр - күңел лирикасы. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Тезмә сөйләм үзенчәлекләре. **(1 сәгать).**

**Ә.Еникинеңтормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Әйтелмәгән васыять» хикәясе.Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе. **( 2 сәгать).**

**Ш.Хөсәеновныңтормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Әни килде» драмасы. Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләр. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). **(2 сәгать).**

**Г. Сабитовныңтормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Тәүге соклану», “Ярсулы яз” хикәяләре. Композиция: әсәр кору алымнары. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. **(2 сәгать).**

**М.Мәһдиевнеңтормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Без кырык беренче ел балалары» повесте. Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе. Әсәрнең геройлары. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). **(2 сәгать).**

**М.Галиевның тормыш юлына кыскача күзәтү. “Уйна әле” хикәясе.** Эпик жанрлар турындагы белемнәрне киңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Тема, проблема, идея. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре**. (1сәгать).**

**Г.Гыйльмановныңтормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Язмышның туган көне» хикәясе. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары. **(2 сәгать).**

**З.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Сәер кыз» драмасы. Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләре. Тема, проблема, идея. Идеал. Сәнгати алымнар һәм стиль. **(1 сәгать).**

**Р.Харисның тормыш юлына кыскача күзәтү. «Сабантуй» поэмасы.** Лиро-эпик жанр - поэма. Лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр.

**(1 сәгать)**

**Р. Фәйзуллинның тормыш юлына кыскача күзәтү.** “Биеклек”, “Туган тел турында бер шигырь” әсәрләре, лирик жанрларны тану күнекмәсен үстерү, лирик герой сыйфатларын билгеләү. **(1 сәгать)**

**Йомгаклау контроль эше (тест) (1 сәгать)**

**Бәйләнешле сөйләм үстерү – 5 сәгать.**

**Сочинение язу өчен үрнәк темалар:**

- “Минем милләтем – минем горурлыгым”-2 сәгать
- “Бәхет – үз-үзеңә тугры калуда” -1 сәгать
- Акъәби образына характеристика язу- 1сәгать
- “Шинельле һәм шинельсез солдатлар”-1 сәгать

**Дәрестән тыш уку өчен – 1 сәгать.**

- Г. Исхакый “Кәҗүл читек”.

**Яттан өйрәнү өчен әсәрләр.**

- “Идегәй” дастаны (өзек).
- Г.Тукай. “Милли моңнар” шигыре.
- Һ. Такташ. “Мокамай” поэмасы (өзек)
- С. Хәким. “Әнкәй” шигыре.
- Р.Фәйзуллин. “Туган тел турында бер шигырь” (өзек).

***Искәрмә:*** *1 нче чиректә 17 сәгать укытылды. Тиеш- 16 сәгать. 2 нче чиректән эш программасы атнага 1 сәгать исәбеннән төзелде. 27 сәгать ( 27 атна)-1 сәгать =26 сәгать . Барлыгы – 43 сәгать.*

# Календарь-тематик планлаштыру

7 нче сыйныф татар әдәбияты

**Дәреслек:** Әдәбият. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә. 1 кисәк / Д.М. Абдуллина, Л.К. Хисмәтова, Ф.Х. Җәүһәрова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 167 б.;

Әдәбият. 7 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 2 кисәктә. 2 кисәк / Д.М. Абдуллина, Л.К. Хисмәтова, Ф.Х. Җәүһәрова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 191 б..

| № | Дәрес темасы | Сәгать саны | Үткәрелгән вакыт | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт | |
| • | Сәнгать төре буларак әдәбият | 1 | 02.09 | | |
| • | Халык авыз иҗатының бер жанры буларак дастан. | 1 | 07.09 | | |
| • | “Идегәй” дастанының идея-проблематикасы | 1 | 09.09 | | |
| • | “Идегәй” дастанының сәнгатьчә эшләнеше | 1 | 14.09 | | |
| • | XX гасыр башында сүз сәнгате | 1 | 16.09 | | |
| • | Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты. “Милләтә”шигыре | 1 | 21.09 | | |
| • | Г.Тукай. “Милли моңнар”шигыре | 1 | 23.09 | | |
| • | Г.Тукай. “Шагыйрь”, “Театр” шигырьләре | 1 | 28.09 | | |
| • | **БСҮ.** “Милләтем – минем горурлыгым” | 1 | 30.09 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| • | **БСҮ.** “Милләтем – минем горурлыгым” | 1 | 05.10 | | |
| • | Н.Думавиның тормыш юлы һәм иҗаты. «Яшь ана» хикәясе | 1 | 07.10 | | |
| • | Н.Думави. «Яшь ана» хикәясендә күтәрелгән проблемалар | 1 | 12.10 | | |
| • | Н.Думави. «Яшь ана» хикәясенең сәнгатьчә эшләнеше | 1 | 14.10 | | |
| • | Ш.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты. «Акчарлаклар» повесте | 1 | 19.10 | | |
| • | Ш.Камал. «Акчарлаклар» повестеның идея-проблематикасы | 1 | 21.10 | | |
| • | Ш.Камал. «Акчарлаклар» повестеның сәнгатьчә эшләнеше | 1 | 26.10 | | |
| • | 1920-1930 нчы еллар әдәбияты | 1 | 28.10 | | |
| 18 | **Һ.Такташның тормыш юлы, иҗаты. Шагыйрь иҗатының үзенчәлеге. “Мокамай” поэмасын уку.** | 1 | 11.11 | | |
| 19 | “Мокамай” поэмасын уку, анализлау. Лиро-эпик жанр буларак поэма | 1 | 18.11 | | |
| 20 | Г.Исхакыйның томыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге. “Җан Баевич” комедиясе | 1 | 25.11 | | |
| 21 | Г.Исхакыйның “Җан Баевич” комедиясе. Әсәрнең сюжет – композициясе, образлар бирелеше | 1 | 02.12 | | |
| 22 | **Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.** “Бәхет – үз-үзеңә тугры калуда” темасына сочинение | 1 | 09.12 | | |
| 23 | **Дәрестән тыш уку. Г. Исхакый “Кәҗүл читек”** | 1 | 16.12 | | |
| 24 | Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повесте | 1 | 23.12 | | |
| 25 | Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повестеенда образлар бирелеше | 1 | 13.01 | | |
| 26 | XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты. С.Хәким иҗаты турында белешмә. . “Әнкәй , “Бу кырлар, бу үзәннәрдә” шигырьләре. Лирик герой, күңел лирикасы, пейзаж лирикасы, табигать бирелеше. | 1 | 20.01 | | |
| 27 | Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗаты. “Әйтелмәгән васыять” хикәясе. Образлар системасы. | 1 | 27.01 | | |
| 28 | Ә.Еникинең“Әйтелмәгән васыять” хикәясе. Хикәянең төп идеясе, темасы,күтәрелгән проблемалары . | 1 | 03.02 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Аллегория күренешләре | | | | |
| 29 | **Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.** Акъәби образына характеристика язу | 1 | 10.02 | | |
| 30 | Шәриф Хөсәеновның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә.Драма төре, аның жанрлары һәм үзенчәлекләре.” Әни килде” драмасының темасы, идеясе, проблемасы | 1 | 17.02 | | |
| 31 | Ш. Хөсәенов “Әни килде” драмасының образлар системасы, әһәмияте | 1 | 24.02 | | |
| 32 | Г. Сабитовның тормыш һәм иҗат юлына күзәтү ясау. “Тәүге соклану” хикәяс**е** | 1 | 03.03 | | |
| 33 | Г. Сабитов “Ярсулы яз” хикәясе. Мәктәп тормышының үзенчәлекле детальләрдә чагылуы. Укучы һәм укытучы мөнәсәбәтләрен, табигатьне бала күңеле һәм хисләре аша тасвирлау.Телнең сурәтлелеге. | 1 | 10.03 | | |
| 34 | Мөхәммәт Мәһдиевның тормыш һәм иҗат юлына күзәтү. “Без – кырык беренче ел балалары” повесте**.** Бөек Ватан сугышы авырлыкларының әсәрдә чагылышы. | 1 | 17.03 | | |
| 35 | Мөхәммәт Мәһдиевның “Без – кырык беренче ел балалары”. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт**.** «Мин» образы, аның бирелү үзенчәлеге. Персонаж һәм вакыйгаларның нечкә юмор белән сурәтләнеше. | 1 | 24.03 | | |
| 36 | **Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.** “Шинельле һәм шинельсез солдатлар”. | | 07.04 | | |
| 37 | М.Галиев “Уйна әле” хикәясе | 1 | 14.04 | | |
| 38 | Галимҗан Гыйльмановның тормыш һәм иҗат юлы “Язмышның туган көне” хикәясе | 1 | 21.04 | | |
| 39 | Галимҗан Гыйльмановның “Язмышның туган көне” хикәясендә образлар. Әсәрнең сюжеты,аның элементлары, пафосы | 1 | 28.04 | | |
| 40 | Зөлфәт Хәкимнең тормыш юлы, иҗаты. “Сәер кыз” драмасы | 1 | 05.05 | | |
| 41 | Ринат Харисның тормыш юлы, иҗаты. “Сабантуй” поэмасы | 1 | 12.05 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 42 | **Йомгаклау контроль эше** | 1 | 19.05 | | |
| 43 | Равил Фәйзуллинның тормыш юлы, иҗаты. “Туган тел турында бер шигырь»<br>Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.Йомгаклау | 1 | 26.05 | | |